# «Бар кеше изгелек кылса, яктырыр иде дөнья»



Ходай безне яраткан,
Төрле җиргә тараткан.
Акыл биргән,тел биргән,
Иман биргән,дин биргән.
Кояш биргән,Ай биргән.
Җир дигән зур табынга
Нигъмәтләрен бай биргән.
Эшләр өчен кул биргән,
Сайлар өчен юл биргән.
Килгән кадәр кулыңнан
Яхшылыклар кыл дигән.



# Нәрсә соң ул игелек?

**Игелек** – ул яхшылык ,изгелек, яхшылыкка җавап итеп кайтарылган яхшылык.



# Тылсымлы сүзләр

1.Сәлам юллыйм мин һәркөн:
Туган телемдә-хәерле.......

2.Тәмле ризыклар пешерә,
Безгә бит ничек рәхәт.
Чын йөрәктән әйтәбез без:
”Тәмле булды,әни,.....”
3.Ялгышкан вакытлар да була бит
Әйтәбез шунда : ”Зинһар,.......”

4.Аерылышканда биреп кул
Без әйтәбез : ”Дустым,.........”

**Шәүкат Галиевның”Рәхмәтләр турында” шигыре**

Җиргә төшкәч
Бияләен,
Гафур алып
Биргән иде,
Динә аңа:
- Рәхмәт, - диде.
Малайның да
Җылы сүзгә
Кәеф килде.
Елмайды да:
-Рәхмәтеңә
Рәхмәт! – диде.
Кыз җавапсыз
Калсын диме?
Җавап бирде:
-Рәхмәтемә
Рәхмәт өчен
Рәхмәт инде!
Малай аңа
Башын иде:
-Рәхмәтемә
Рәхмәт өчен
Рәхмәтеңә
Рәхмәт, -диде.
Динә көлде.
Бик күңелле,
Рәхәт иде.
... Җиргә төшкән
Бияләйгә
Рәхмәт инде.



# Балама нәсихәт

***Иң беренче, кеше белән***
***Исәнләш үзең.***
***Чытык булма,борын чөймә,***
***Балкысын йөзең.***
***Беркайчан да, балакаем,***
***Кешедән көлмә.***
***Тыңлый да бел, сөйләгәндә***
***Сүзен бүлдермә.***
***Яман сүз белән күңелгә***
***Җәрәхәт салма.***
***Хәрәм малга кулың сузып,***
***Оятка калма.***
***Туганнарың, дустың белән***
***Ризыгыңны бүл.***
***Ятимнәргә, гарипләргә***
***Мәрхәмәтле бул.***
***Вөҗданыңны, намусыңны***
***Беркайчан сатма.***
***Кырын эш белән чуалып,***
***Тормышың ватма.***
***Авырлыклар килгән чакта***
***Тагын шул сүзем:***
***Кирәк, балакай, өйрән син***
***Булырга түзем.***

***Роза Мәсләхова***
***Нурлат районы,Киекле авылы.***

# Уйлап кара

## Трамвайда.

**Рамил бара вокзалга**
**Трамвайга утырып**
**Басып тора бер бабай**
**Утыргычка тотынып**
**Үткәч ике тукталыш,**
**Барып җиткәч вокзалга,**
**Рамил торды җай гына,**
**Урын бирде бабайга.**
**Күргәч шундый игътибар**
**Бабай аптырап кала:**
**Мин утырсын дип төште,**
**Нинди тәүфыйклы бала!**







# Ялкау да үсә

Иренә ул укырга,
Иренә ул эшләргә,
Иренсә дә,барыбер
Туры килә үсәргә.



Әкрен кыймылдаса да,
Тиз үтәчәк балачак.
***Бала ялкау*** үскәчтән
***Ата ялкау*** булачак!




Мәктәп изгелеккә,
яхшылыкка өйрәтә.

# Дуслык кануннары

1.Дустыңны үртәмә,түбәнсетмә.
2.Авырлык килгәндә ярдәм ит.
3.Шатлыгыңны дустың белән бүлешә бел. 4. Дустыңның кимчелекләреннән көлмә.
5.Дустыңны киеменә карап түгел,яхшы сыйфат-ларына карап сайла.
6.Хаталарыңны таный бел,тәнкыйтьне дөрес аңла.
7.Дустыңны бер вакытта да сатма.

“Дога белмим дисең нигә
Яхшылык-үзе дога!
Бар кеше изгелек кылса,
Яктырыр иде дөнья...”



# Яшәвеңнең мәгънәсе



Актыккы сулышны алганда
Уфтанмас өчен җан,ачынып-
Кулларда егәрлек барында,
Яхшылык эшләргә ашыгыйк.
Күтәрик егылган гөлләрне,
Матурлык калмасын басылып.
Холкыбыз бик сабыр булса да,
Яхшылык эшләргә ашыгыйк.
Булмасын нәфсебез безгә баш,
Без аңа үзебез баш булыйк.
Яманлык җиңелсен дисәк без,
Яхшылык эшләргә ашыгыйк.
Ходаның һәр бирмеш көнендә
Бер матур як белән ачылыйк:
Һәркемнең гомере бер генә,
Яхшылык эшләргә ашыгыйк.




Игътибарыгыз
өчен бик зур
рәхмәт!